РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 45

2021 елның 30 июле

Шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга дәүләт, шул исәптән мөлкәти ярдәм чаралары күрсәтү мөмкинлеге максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Советының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының – ярдәм алучыларның бердәм реестрын формалаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 1 һәм 2 статьялары нигезендә, шулай ук шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга (алга таба - үзмәшгуль гражданнар) дәүләт һәм муниципаль, шул исәптән мөлкәти ярдәм чаралары күрсәтү мөмкинлеге максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының «Муниципаль милек исемлегенә кертелгән, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә файдалануга бирү өчен, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибен раслау турында» 2016 елның 20 октябрендәге 54 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктта «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә файдалануга бирү өчен» сүзләреннән соң «шул исәптән шәхси эшмәкәрләр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга (алга таба – үзмәшгуль гражданнар)» сүзләрен өстәргә;

1.2. Түбән Кама муниципаль районы Советы карары белән расланган Тәртипнең 1.1 пунктында «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә файдалануга бирү өчен» сүзләреннән соң «шул исәптән үзмәшгульләргә» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктында «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә файдалануга бирү өчен» сүзләреннән соң «шул исәптән үзмәшгульләргә» сүзләрен өстәргә;

1.6 пунктта «Исемлеккә кертелгән мөлкәт арендаторлары кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары булырга мөмкин» сүзләреннән соң «шул исәптән үзмәшгульләр» сүзләрен өстәргә.

2. «Муниципаль милек исемлегенә кертелгән, Өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә милеккә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милек исемлеген формалаштыру, алып бару, бастырып чыгару тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 20 октябрендәге 53 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1 1 пунктта «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә милеккә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән» сүзләреннән соң «шул исәптән үзмәшгульләргә» сүзләрен өстәргә;

2.2 Түбән Кама муниципаль районы Советы карары белән расланган Нигезләмәнең 1.1 пунктында «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә милеккә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән» сүзләреннән соң «шул исәптән үзмәшгульләргә» сүзләрен өстәргә;

2.3 1.2 пунктта «Исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәт кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына озак вакытка исәпләнгән нигездә милеккә һәм (яки) файдалануга тапшыру максатларында файдаланылырга мөмкин» сүзләреннән соң «шул исәптән үзмәшгульләргә» сүзләрен өстәргә;

2.4 1.3 пунктта «исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәт, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милкенә мондый мөлкәтне түләүле читләштерүдән тыш, шәхси милеккә күчерелергә тиеш түгел» сүзләреннән соң «шул исәптән үзмәшгульләргә» сүзләрен өстәргә;

2.5 2.1 пунктта «кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү өчен муниципаль мөлкәт исемлегенә» сүзләреннән соң «шул исәптән үзмәшгульләргә» сүзләрен өстәргә;

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы — А.Р.Метшин